# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Шәпше авыл җирлегенең Шәпше ав. торак пунтында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

24.11. 2020 ел № 3

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “2021 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше ав. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:

а) Шәпше авылы зиратына (Ключи) юл төзү өчен смета һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, таш ташу, вак таш җәю, смета буенча түләү (Ключи));

б) Шәпше авылы зиратын киртәләп алу, смета һәм килешү буенча түләү;

в) Шәпше авылында янгын гидрантларын урнаштыру өчен гидрантлар сатып алу, смета һәм килешү буенча эшләр өчен түләү

үтәү буенча юллау белән килешәсезме?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча 2020 елның 13 ноябрендә, 2020 елның 20 ноябрендә, 2020 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 997 (тугыз йөз туксан җиде) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 551 кеше, бу 55 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 545 (биш йөз кырык биш) катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 6 (алты) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Шәпше авыл җирлеге Шәпше ав. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авылы җирлеге Шәпше ав. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм

даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) суммада үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) Шәпше авылы зиратына (Ключи) юл төзү өчен смета һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, таш ташу, вак таш җәю, смета буенча түләү (Ключи));

б) Шәпше авылы зиратын киртәләп алу, смета һәм килешү буенча түләү;

в) Шәпше авылында янгын гидрантларын урнаштыру өчен гидрантлар сатып алу, смета һәм килешү буенча эшләр өчен түләү.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче В. А. Беляков